ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ БАЙСАР АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423745, Иске Байсар авылы,
Мэктэп урамы, 44а нче йорт.
Тел.(885552)3-44-53.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АКТАНЫШ-
СКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СО-
ВЕТ СТАРОБАЙСАРОВСКОГО СЕЛЬ-
СКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423745, с. Старое Байсарово, ул. Школь-
ная, дом 44а. Тел.(885552) 3-44-53.
E-mail bay.akt@yandex.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**«25» июнь 2024 ел** **№ 11**

Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлегенең
җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең
бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә, Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советына Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетына Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Актаныш муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимнәрне кабул иткән очракта, Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге башкарма комитетына:

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан, 2024 елга 2025 һәм 2026 еллар план чорына Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге бюджеты турында карарга үзгәрешләр кертү хакында Актаныш муниципаль районы Иске Байсар авыл җирлеге Советы карары проектын әзерләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Кадыйров Р.М.